**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 08 июне** **№ 86**

**"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 44 нче статьясы нигезендә, 2004 елның28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы,"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 88,89,90 статьялары нигезендә, "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы КАРАР чыгарды:

1. "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Түбәндәге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсендә теркәлгәннән соң, түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмати стендларда урнаштырырга:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы урамы, 9 йорт (мәдәният йорты бинасы);
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов урамы, 9 йорт (мәдәният йорты бинасындагы китапханә), шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә. Кушымтаның 1 пунктындагы “б” пунктчасы 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы** **А.Г. Җиһаншин**

"Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге Советы
карарына кушымта
86 номер,08 июнь, 2018 ел

**"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр**

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. 7 маддәдә:

а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) җирлек территориясенең төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен оештыруга контрольлек итү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру

б) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14) каты коммуналь калдыкларны җыю һәм озату буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу (шул исәптән аерым җыюга);”

2. 8 маддәдә:

а) маддәнең 1нче өлешен түбәндәге эчтәлекле 16 пункт белән тулыландыру:

“16) инвалидларның, мөмкинлекләре чикле кешеләрнең физик культура һәм спорт үсешенә ярдәм күрсәтү (адаптив физик культура һәм адаптив спорт)

б) 12 пунктны үз көчен югалткан дип таныргга.

3. 14 маддәнең 7 пунктын түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:

“иҗтимагый фикер алышу”

4. 23 маддәнең 3 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункты белән тулыландырырга:

«2.1) җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проекты;»;

б) 3 пунктта “муниципаль берәмлекнең планнары проектларын һәм үсеш программаларын” сүзләрен төшереп калдырырга.

5. 36 маддәдә:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункты белән тулыландырырга:

«5.1) муниципаль идарә итүнең озак вакытлы максатларын һәм бурычларын һәм җирлекнең социаль-икътисади үсешен билгеләү, җирлекнең үзидарә

органнарының вәкаләтләренә кагыла торган мәсьәләләре буенча стратегик планлаштыруның документларын карау һәм раслау (хуплау);»;

в) 36 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«36) җирлек территориясенең төзекләндерү кагыйдәләрен раслау»;

г) 38пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38) Россия Федерациясе Хөкүмәте таләпләре тарафыннан билгеләнгән, җирлекнең коммуналь инфраструктура системалары үсешенең комплекслы программаларын, җирлекнең транспорт инфраструктурасы үсешенең комплекслы программаларын, җирлекнең социаль инфраструктурасы үсешенең комплекслы программаларын раслау;».

6. 47 маддәнең 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) җирлекнең Совет утырышына җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектын тәкъдим итә;».

7. 53 маддәнең 1 өлешенең 1пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) планлаштыру, бюджет, финанслар һәм исәп алу өлкәсендә:

- җирлекнең бюджет проектын, җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектын әзерли;
- җирлек бюджетының үтәлешен тәэмин итә, җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе үтәлешен оештыра;
- җирлекнең бюджетының үтәлеше, җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе үтәлеше турында хисап әзерли;
- Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән мәгълүматларны дәүләт хакимияте органнарына билгеләнгән тәртиптә җирлекнең икътисадының халәтен һәм социаль өлкәсен характерлаучы

статистик күрсәткечләрне җыюны оештыра,

- җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын эшләү һәм тормышка ашыру;
- җирлек Советы тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту һәм мониторинг;».

8. 54 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«54. Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә җирлекнең Башкарма комитеты хокукы

Башкарма комитет җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән

түбәндәге вәкаләтләрне тормышка ашыра:

- җирлек музейлары булдыра;
- җирлектә нотариус булмаган очракта, законлылык тарафыннан каралган нотариаль гамәлләр кыла;
- опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне тормышка ашыруда катнаша;
- җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләр хокукларын гамәлгә ашыру белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар булдыра;
- Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны тормышка ашыруга ярдәм күрсәтә;

- җирлек территориясендәге муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр мобилизацион әзерлеге буенча чаралар оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

- җирлектә янгыннан саклауны булдыра;

- туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;

- мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык итү йөзеннән иҗтимагый җәмәгать контроле белән тәэмин итү өчен күзәтчелек комиссияләренә ярдәм күрсәтә;

- инвалидларның җәмәгать оешмаларына, шулай ук 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендәге инвалидларны социаль яклау турында"гы Федераль закон нигезендә гомумроссия җәмәгать берләшмәләре тарафыннан төзелгән инвалидлар оешмаларына ярдәм күрсәтә;

- торак законлылыгы нигезендә, гражданнарга торак биналарның муниципаль социаль файдалану фондыннан найм килешүе белән торак бина бирә;

- авыл җирлеге территориясендә яшәүче караучысыз асралучы хайваннарны аулау һәм карап тору буенча чараларны гамәлгә ашыра;

- 2016 елның 23 июнендәге182-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә хокук бозулар профилактикасының төп системасы турында"гы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыра;

- инвалидларның, мөмкинлекләре чикле кешеләрнең физик культура һәм спорт үсешенә ярдәм күрсәтә (адаптив физик культура һәм адаптив спорт)"

9. 73 маддәнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Кешенең һәм гражданинның хокукый статусын билгели торган, оешмаларның хокукый статусын гамәлгә куючы, учредителе җирлек булган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасындагы килешүләр, аларны рәсми бастырып чыгарганнан(халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

10. 83маддәнең 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Гражданнарның үзара салымы чаралары, җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен, гражданнарның бер тапкыр түләүләре дигәнне аңлата.

Гражданнарның үзара салым түләү тәртибендәге түләүнең күләме җирлектәге (җирлек составына керүче торак пункт ) барлык кеше өчен абсолют зурлыгы тигез рәвештә билгеләнә, чыгарма: саны җирлектәге халыкның гомуми санының 30 процентыннан артмаган гражданнарның аерым категориясе н исәпкә алып.

10. 88 маддәнең 3 өлешеннең икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль берәмлекнең уставына Россия Федерациясенең Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл күрсәтү формасында үзгәрешләр кертелгән очракта үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт проекты буенча исәпкә алу тәртибе тәкъдимнәрен, шулай ук аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен испкә алып әлеге устав белән шушы норматив хокукый актларны туры китерү максатларында, рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) кирәк түгел."

11. 90 маддәдә:

а) 3нче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Хәзерге уставка җирле үзидарә органнарының структура үзгәреше турындагы үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы җирлек башлыгы тарафыннан имзаланган хокуки акт (федераль законнарга туры китерүдән, вәкаләтләр үзгәреше, вазифаи затларның сайлану тәртибе башка) җирлек башлыгының вәкаләтләре тәгәлләнгәч кенә үз көченә керә.”;

б) түбәндәге эчтәлекле 3.1 бүлеге белән тулыландырырга:

“Хәзерге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы хокуки акт түбәндәгечә кабул ителергә мөмкин:

1) җирлек башлыгы һәм совет рәисе яки совет рәисе вәкаләтләрен башкаручы

җирлек башлыгы тарафыннан имзаланган Совет (халык җыены) карары нигезендә;

2) Совет (халык җыены) тарафыннан кабул ителгән һәм җирлек башлыгы тарафыннан имзаланган аерым норматив хокуки акт нигезендә. Бу очракта хокуки актта кабул итү реквизитлары куела.Мондый Совет карарында күчеш чоры яки үзгәрешләр һәм өстәмәләр көченә кертү нормасы билгеләү рөхсәт ителми.”;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 бүлек белән тулыландырырга:

“5. Җирлек уставларын федераль һәм Республика Татарстан законнарга туры китерү бу законнарда каралган срокларда хәл ителә. Әгәрдә бу законнарда уставка үзгәрешләр кертү срогы билгеләнмәгән булса, үзгәрешләр кертү срогы законнарның үз көченә керү срогын, закон тарафыннан билгеләнгән уставка үзгәрешләр кертү процедураларын, шул исәптән дәүләт теркәвен һәм игълан итү (халыкка җиткерү) срогын исәпкә алып алты айдан артмаска тиеш.”;

Түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек белән тулыландырырга:

«6. Җирлек уставын җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт белән яңа редакциядә аңлату рөхсәт ителми.

Бу очракта җирлекнең яңа уставы кабул ителә, ә җирлекнең элеккеге гамәлдәге уставы һәм үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакындагы муниципаль хокукый актлар, җирлекнең яңа уставы үз көченә кергән көннән алып, үз көчләрен югалткан дип санала.”